ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **КҮРСӘТМӘ**

«12» апреля 2021 ел № 72-р

Әгерҗе муниципаль районында «Аҗаган - 2021» хәрби-спорт уенының муниципаль этабын үткәрү турында

Яшьләрне һәм яшүсмерләрне хәрби-патриотик юнәлештәге чараларда катнашуга җәлеп итү, оборона-спорт күнекмәләрен һәм осталыкларын камилләштерү, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, Россиянең булачак сакчыларына кирәкле сыйфатлар һәм күнекмәләр формалаштыру, яшьләр һәм яшүсмерләрне Россия Федерациясе Кораллы көчләрендә хезмәткә әзерләү максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2015 елның 28 гыйнварындагы 39-1 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Уставы нигезендә:

1. «Аҗаган - 2021» хәрби-спорт уенының муниципаль этабын уздыру турында Нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләре үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенә 2021 елның 16 апрелендә «Аҗаган - 2021» хәрби-спорт уенының муниципаль этабын (алга таба - хәрби-спорт чарасы) оештырырга һәм уздырырга.
3. Спорт чарасын үткәрү урыны дип Татарстан Республикасы, Әгерҗе ш., Гагарин ур., 56 йорт («Татарстан Республикасы Әгерҗе шәһәренең 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МББУ бинасы) билгеләргә.
4. 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенә хәрби-спорт чараларын уздыру өчен урын әзерләүне оештырырга.
5. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының мәгариф учреждениеләрен әлеге боерык белән таныштырырга.
6. «Әгерҗе үзәк район хастаханәсе» ДАССУга хәрби-спорт чарасы чорында медицина ярдәмен тәэмин итүне тәкъдим итәргә.
7. Россия Эчке эшләр министрлыгының Әгерҗе районы буенча бүлегенә хәрби-спорт чарасын үткәргәндә иминлекне һәм озата баруны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

8. «Татмедиа» АҖ филиалы - «Әгерҗе хәбәрләре» Әгерҗе районы газетасына, «Әгерҗе радиосына» массакүләм мәгълүмат чараларында хәрби-спорт чарасын үткәрү һәм уздыру турында яктыртуны оештырырга тәкъдим итәргә.

9. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (Баженова О.А.) әлеге күрсәтмәне гамәлгә ашырганда финанслау мәсьәләсен хәл итәргә.

10. Әлеге күрсәтмәне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы (https://agryz.tatarstan.ru) составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга

11. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының спорт һәм туризм бүлеге башлыгы Л.С. Имановага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**